КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 29 октябрь г.Казань № 954

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Мөслим авылында урнашкан «Сарман аграр көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе филиалын бетерү һәм аның базасында «Мөслим политехника техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесен төзү турында

Һөнәри белем бирү белән идарә итү системасын камилләштерү һәм уку-укыту-тәрбия бирү барышын оештыруны тикшерүдә тотуны көчәйтү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Татарстан Республикасы, Мөслим муниципаль районы, Мөслим авылы, Яшьләр урамы, 15 нче йорт адресы буенча урнашкан «Сарман аграр көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе филиалын (алга таба – Мөслим филиалы) бетерү һәм аның базасында Россия Федерациясе законнарында каралган эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләрен үтәү өчен һәм урта һөнәри белем бирү программасын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтү максатларында мөстәкыйль юридик зат - «Мөслим политехника техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесен төзү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

«Мөслим политехника техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесен (алга таба - Мөслим политехника техникумы) гамәлгә куючы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашырырга;

өч эш көне эчендә Мөслим филиалын бетерү турында кабул ителгән карарны теркәүче органга хәбәр итәргә;

14 көн эчендә:

Мөслим филиалын бетерү комиссиясе составын расларга;

Мөслим филиалын бетерү тәртибен һәм вакытларын Россия Федерациясе Граждан кодексы нигезендә билгеләргә;

30 көн эчендә:

«Сарман аграр көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе (алга таба - Сарман аграр көллияте) уставына үзгәрешләр кертергә;

Мөслим политехника техникумы уставын эшләргә һәм расларга;

Сарман аграр көллиятендә һәм Мөслим политехника техникумында укучыларны әзерләү алып барылачак белгечлекләр исемлеген билгеләргә;

Сарман аграр көллияте һәм Мөслим политехника техникумы өчен гамәлгә куючының дәүләт йөкләмәсен эшләргә;

Мөслим филиалында укучыларны Мөслим политехника техникумына, Мөслим филиалында гамәлдә булган уку-укыту шартларын һәм программаларын саклап, ата-аналар (законлы вәкиләр) ризалыгы белән күчерергә;

Мөслим филиалын бетерү буенча законнарда күздә тотылган башка чараларны гамәлгә ашырырга, шулай ук бетерелү аркасында эштән азат ителә торган хезмәткәрләргә Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына Мөслим политехника техникумына оператив идарә хокукында тапшырылырга тиешле мөлкәте исемлеген, шулай ук күчемсез мөлкәт объектларына техник документацияне Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына кертергә.

3. Мөслим политехника техникумының дәүләт йөкләмәсен үтәвен финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карарында билгеләнгән тәртиптә, тиешле финанс елына күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы бюджеты хакында Татарстан Республикасы законында каралган акча кысаларында гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына:

30 көн эчендә бу карарның 2 нче пунктынңа күрсәтелгән мөлкәт исемлеген Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы биргәннән соң оператив идарә хокукында Мөслим политехника техникумына беркетергә;

Мөслим политехника техникумына беркетелә торган күчемсез мөлкәт объектлары урнашкан җир кишәрлекләрен даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында 120 көн эчендә бирергә.

5. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә, бу карарның 2 – 4 пунктларын үтәгәннән соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасы һөнәри белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын билгели торган норматив хокук актларына аларны бу карарның 1 пункты нигезендә туры китерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр әзерләргә һәм аларны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин